**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 1а, село Верхняя Каменка, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ СОВЕТЫ**
Дружба урамы, 1а йорт, Югары Кәминкә авылы, 423108

тел./факс (84396) 2-31-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 106 21 декабрь 2018 ел

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы Карары**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 нче февралендәге 47 номерлы «Чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 елның 3 августындагы 307-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" гы Федераль законына, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 27.1 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:
1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының 20.02.2013 елдан № 47 «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының «Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм аларга каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен чикләүләр һәм тыюлар, таләпләрне үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турында " гы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:
Пункт 2.5. Нигезләмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: Муниципаль хезмәткәрләргә карата дисциплинар җәза яллаучы (эш

бирүче) вәкиле булган җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан кулланыла:

1) коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органнарның кадрлар бүлеге тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;
2) тикшерү нәтиҗәләре турында доклад комиссиягә җибәрелгән очракта, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия тәкъдимнәре;
3) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе доклады, анда аны башкаруның факттагы шартлары бәян ителә, һәм муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмасын бары тик аның ризалыгы белән генә һәм коррупциячел хокук бозу фактын тану шарты белән (ышаныч югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге түләтүне кулланудан тыш);
4) муниципаль хезмәткәр аңлатмалары;
5) башка материаллар.

2.Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында басылып чыкканнан соң (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырганнан соң законлы көченә керә.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге башлыгы К. М. Гыйләҗев